**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 04 2020 № 244

Аксубаево

Аксубай муниципаль районында
тормыш дәрәҗәсен күтәрү
һәм керемнәрне легальләштерү буенча
район ведомствоара комиссиясе
турындагы нигезләмәне раслау хакында

Районда халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, формаль булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне җиңү буенча алга таба эшне башкаруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Президентының «Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча Республика ведомствоара комиссиясе мәсьәләләре» 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-891 номерлы Указының 3 пунктын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Аксубай муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә (1 нче кушымта);

1.2. Аксубай муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составы (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://Aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасары И.И. Моратшинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының
«16» 04 2020 № 244
карарына 1 нче кушымта

**Аксубай муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә.**

1. Аксубай муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе (алга таба - Комиссия) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының (алга таба - федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары) һәм җирле үзидарә органнарының килешенгән гамәлләрен тәэмин итү, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, формаль булмаган хезмәт базарын киметү һәм икътисадтагы тискәре тенденцияләрне җиңү буенча коллегиаль ведомствоара орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына,муниципаль хокукый актларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3.Комиссиянең төп функцияләре һәм бурычлары:

- социаль-икътисадый өлкәдә тенденцияләр мониторингын үткәрү, шулай ук район муниципаль хакимияте органнары тарафыннан әлеге өлкәдә кабул ителә торган карарларның халыкның тормыш сыйфатына йогынты ясавы;
- хезмәт базарын тотрыклыландыру, керемнәрне легальләштерү, район икътисадында күләгә икътисады һәм формаль булмаган хезмәт базары йогынтысы нәтиҗәсендә барлыкка килгән тискәре тенденцияләрне җиңү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү;
- эш бирүчеләрнең минималь куллану бюджетының бәясеннән ким булмаган күләмдә хезмәт хакын вакытында түләвен тәэмин итүгә һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен түләүгә, шулай ук халыкның, шул исәптән пенсия яшендәге гражданнарның реаль керемнәрен арттыру буенча чараларны эшләү;
- формаль булмаган икътисад һәм хезмәт базары тенденцияләрен һәм масштабларын ачыклау максатыннан социологик тикшеренүләр үткәрү турында тәкъдимнәр әзерләү;
- район территориясендә урнашкан барлык оештыру-хокук рәвешләрендәге хуҗалык итү объектларының чыгымнар структурасын үзгәртүгә анализ, әлеге базада өстәмә кыймматне арттыру, хезмәт хакын арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү;

- кризис хәлендә булган хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеген мониторинглау, милекчеләр тарафыннан үз вакытында идарә итү карарларын кабул итү һәм хуҗалык итүче субъектларның аңлы рәвештә барлыкка китерелүен яисә түләмәүчәнлеген арттыруга юнәлтелгән гамәлләрне тормышка ашыру өчен тәкъдимнәр эшләү максатында;

- җирле үзидарә органнары инициативасы буенча район территориясендә урнашкан аерым хуҗалык итүче субъектларның бөлгенлеккә төшүен кисәтү чаралары турында тәкъдимнәрне анализлау, шулай ук күрсәтелгән хуҗалык итүче субъектларга карата мөстәкыйльлек (банкротлык) процедураларын башлап җибәрүгә вәкаләтле органнарны карауга әзерләү һәм кертү.

- районда социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын, адреслылыгын һәм үтемлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләү.

4. Комиссия хокуклы:

- үз утырышларына җирле үзидарә башкарма органнарының, территориаль башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының җитәкчеләрен һәм башка вазыйфаи затларын, шулай ук эшче төркемнәр (Советлар, комиссияләр), хуҗалык итүче субъектларның җитәкчеләрен чакырырга;

- башкарма хакимият органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук хуҗалык итүче субъектлардан комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча кирәкле документларны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга һәм алырга;

- комиссия ачыклаган бозуларны бетерү максатларында законнар нигезендә карарлар кабул итү өчен башкарма хакимият органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына мәгълүмат җибәрергә;

- кирәк булганда, тиешле тәртиптә федераль һәм территориаль башкарма хакимият органнары, хуҗалык итүче субъектларның территориаль органнары белгечләрен Комиссия компетенциясенә керүче карарлар һәм башка материалларны әзерләүдә катнашу өчен җәлеп итәргә;

- Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эшче төркемнәр төзү.

5. Комиссия составына Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе башкарма хакимиятенең территориаль органнары, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары вәкилләре керә.

6. Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия рәисе раслаган план буенча башкара.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма айга кимендә бер тапкыр уздырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Утырыш беркетмәсенә комиссия рәисе кул куя.

8. Комиссия Рәисе:

- комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота;

- комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларга рәислек итә;
- Комиссия эшчәнлеген тәэмин итүче карарлар кабул итә.

9. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;
- Комиссия кабул иткән карарларның үтәлеше турында мәгълүмат әзерли.

10.Комиссиянең район Башлыгы, район Башкарма комитеты җитәкчесе карарларын таләп итә торган тәкъдимнәре район Башлыгы, район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан йөкләмәләр һәм карарлар рәвешендә рәсмиләштерелә. Әлеге проектлар Комиссия рәисе тарафыннан визалар һәм карар кабул итү һәм карау өчен район Башлыгына, Башкарма комитет җитәкчесенә җибәрелә.

11.Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү район Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

12.Комиссия үз эшчәнлеген Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты карары буенча туктата.

13.Комиссия карарларына законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының
«16» 04 2020 №244
карарына 2 нче кушымта

**Аксубай муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составы**

**Комиссия рәисе**
Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

**Комиссия рәисе урынбасары**
Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мөлкәт һәм финанслар буенча беренче урынбасары

**Комиссия рәисе урынбасары**
Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары

**Комиссия секретаре**
Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече

**Комиссия әгъзалары:**
Аксубай районы прокуроры өлкән юстиция киңәшчесе (килешү буенча)

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге начальнигы

Аксубай муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча).

Аксубай муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча)

Аксубай муниципаль районы Финанс бюджет палатасы рәисе

«Аксубай муниципаль районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Аксубай муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча)

Аксубай статистика бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты (килешү буенча)

Аксубай муниципаль районында Россия полиция начальнигы урынбасары (килешү буенча)

РПФның Аксубай муниципаль районындагы идарәсе начальнигы (килешү буенча)

Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсенең суд приставларының Аксубай район бүлеге начальнигы (килешү буенча)

ТР Аксубай районы эшмәкәрләр Советы вәкиле

Россия Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 12 нче районара салым түләүчеләр белән эшләү бүлегенең баш дәүләт инспекторы (килешү буенча)

Аксубай муниципаль районы һөнәр берлекләренең координацион Советы рәисе

РФ Федераль миграция хезмәтенең ТР буенча идарәсенең Аксубай ш.т.п. бүлеге начальнигы (килешү буенча).